| | |
|---|---|
| **Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге Советы** |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 12 ноябрь 2020 ел | №14 |

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 218 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2020 елның 1 ноябрендәге 218 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карар исемендә «һәм сроклары турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» карар преамбуласында «һәм сроклары турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктның өченче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- салым түләүче-оешмалар өчен салым түләү, җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше буларак, аванс түләүләре белән башкарыла;».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**